Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XLI-11**

Балык Бистәсе штп. 2019 елның 1 апреле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2013 елның 4 апрелендәге XXVI-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» Федераль законның 7 маддәсенә һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 маддәсенә үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 559-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2013 елның 4 апрелендәге XXVI-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 14.08.2014 ел №XXXIX-3, 13.12.2014 ел XLII-8, 14.11.2015 ел №V-3, 23.04.2016 ел №X-8, 16.11.2016 ел №XIII-9, 29.05.2017 ел №XIX-9, 23.10.2017 ел №XXII-6, 24.07.2018 ел №XXXII-4, 19.11.2018 ел № XXXVI-5, 20.12.2018 ел № №XXXVII-2 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 маддәгә түбәндәге эчтәлектәге 6.5 өлешне өстәргә: “6.5. Граждан муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторы вазыйфасына билгеләнә алмый, ә муниципаль хезмәткәр муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе, муниципаль берәмлек башлыгы, җирле администрация башлыгы, тиешле муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре белән якын туган яки ир (хатын) ягыннан туганлашкан (ата-аналар, ир белән хатын, балалар, ир туганнар, кыз туганнар, шулай ук ир белән хатынның ир туганнары, кыз туганнары, ата-аналары, балалары һәм балаларының ир белән хатыннары) булган очракта муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторы вазыйфаларын били алмый.”

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык  Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык  Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов